| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2014 Казан ш. № 10-50/кс

***Эчә торган суга, техник суга, субүлүгә 2015 елга тарифларны билгеләү турында***

“Су белән тәэмин итү һәм субүлү турында” 2011 елның 7 декабрь № 416-ФЗ Федераль законына, “Су белән тәэмин итү һәм субүлү өлкәсендә тарифларны дәүләт көйләве турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 май № 406 карарына, “2015 елга су белән тәэмин итү һәм субүлү өлкәсендә гамәлдәге тарифларның иң югары күләмдә мөмкин булган үзгәрешен Россия Федерациясе субьектлары буенча уртача соңгы чиктә көйләүне билгеләү турында” тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2014 елның 11 октябрь № 228-э/4 боерыгына, Татарстан республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 15.06.2010 № 468 карары белән раслаган Нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм субүлүне үтәүче оешмалар өчен эчә торган суга, техник суга, субүлүгә тарифларны, шушы карарның кушымтасы белән килештереп, календарга бүлеп билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар, 2015 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр, гамәлдә булачак.

3. Шушы карарның кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән һәм субүлүне тәэмин итүче оешмаларга, су белән тәэмин итү өлкәсендә мәгълүматны җиткерүдә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнвар № 6 карары белән расланган стандартлар нигезендә, алдагы көйләү вакытына кадәр тарифларны билгеләү турында карар кабул иткәнче, 30 календар көннән дә соңга калмыйча, мәгълүматны җиткерергә.

4. Шушы карар рәсми басылгач, ун көннән соң, үз көченә керә.

.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитетының
15.12.2014 № 10-50/кс
карарына

Салкын су белән тәэмин итүне һәм субүлүне үтәүче  оешмалар өчен эчә торган суга, техник суга, субүлүгә, календарга бүлеп, 2015 елга тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) субүлүне үтәүче оешма исеме | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум./куб.м | | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум./куб.м | | Субүлүгә тариф (бер ставкалы), сум./куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2015 дан 30.06.2015 кадәр | 01.07.2015 дән 31.12.2015 кадәр | 01.01.2015 дан 30.06.2015 кадәр | 01.07.2015 дән 31.12.2015 кадәр | 01.01.2015 дан 30.06.2015 кадәр | 01.07.2015 дән 31.12.2015 кадәр |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «ТАНЕКО» ААЖ (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән), тарифларны бүлү технологик үзара бәйләнмәгән үзәкләштерелгән челтәрләр булуга бәйле | 71,02 | 71,02 | 9,61 | 10,05 | | |
| 1.1 | промышленность табигый суларын субүлүдән | | | | | 27,63 | 28,36 |
| 1.2 | көнкүреш табигый суларын субулүдән | | | | | 15,48 | 15,86 |
| 2 | «Түбән Кама ЖЭҮ»  ЖЧЖ (тарифларНДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 45,90 | 47,45 | | | 10,77 | 11,63 |

<*>Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын үтәү максатларында аерып күрсәтелә.

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге